ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 25 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында” 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 21 статьяда:

а) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) дәүләт бүләгенә тәкъдим ителгән гражданга карата җинаять эше кузгатылганда йә ул, җинаять эше башка затларга карата яисә җинаять билгеләре булган гамәл кылу факты буенча кузгатылган булса, гаепләнүче буларак җавапка тартылганда (гражданга карата аклау хөкеме чыгарылганда яисә гражданга карата реабилитацияләү нигезләре буенча җинаять эзәрлекләве туктатылганда тәкъдим яңадан кертелергә мөмкин);”;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

“$3^1$) дәүләт бүләгенә тәкъдим ителгән граждан җинаять кылган өчен үз көченә кергән суд карары нигезендә хөкем ителгәндә (судның үз көченә кергән гаепләү хөкеме юкка чыгарылганда һәм җинаять эше реабилитацияләү нигезләре буенча туктатылганда тәкъдим яңадан кертелергә мөмкин);”;

2) 22 статьяда:

а) 3 өлештә “Татарстан Республикасының рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла” сүзләрен “җәмәгатьчелеккә хәбәр итү максатларында Татарстан Республикасы Президентының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырылырга мөмкин” сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 25 статьяда:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру турында яисә аларны бүләкләнүченең гаиләсенә тапшыру (бирү) турында беркетмә төзелә, ул бүләкне тапшырган зат, яисә тапшыру башкарылган дәүләт органы, җирле үзидарә органы, оешма җитәкчесе, яисә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясенең вәкаләтле әгъзасы тарафыннан имзалана һәм тиешле мөһер белән беркетелә.”;

б) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

“4. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшыру тәртибе Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.”;

4) 32 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Татарстан Республикасы Президенты, гражданны яисә оешманы Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләүгә тәкъдим итү өчен кертелгән документлардагы белешмәләрнең дөрес булмавы билгеләнгән очракта, бүләкләү турындагы указны юкка чыгара яисә бүләкләү турындагы указга үзгәреш кертә.”;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Үзләренә карата бүләкләүне юкка чыгару турында указ яисә бүләкләү турындагы указга үзгәрешләр кертү хакында указ чыгарылган гражданга яисә оешмага тапшырылган Татарстан Республикасы дәүләт бүләге һәм аның документы Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясенә кире кайтарылырга тиеш.”;

в) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 05 май
№ 25-ТРЗ